**Тема 5. Сүзләрнең синтаксик бәйленеше. Сөйләмне оештыручы төп бәйленеш буларак ияртүле бәйленеш.**

письменная работа, примерные вопросы:

Средства подчинительной связи.

**Тема 6. Сүтезмә**

письменная работа, примерные вопросы:

Именные словосочетания Глагольные словосочетания.

**Тема 7. Җөмләнең баш кисәкләре. Баш кисәкләрнең хәбәрлек оештырулары. Ия. Аның төп билгеләре. Хәбәр. Исем хәбәрләр. Фигыль хәбәрләр. Гади һәм тезмә фигыль хәбәрләр. Кушма фигыль хәбәрәр.**

письменная работа, примерные вопросы:

Грамматические схемы и модели простого предложения.

**Тема 8. Иярчен кисәкләр. Иярчен кисәкләрне өйрәнү тарихы.Аергыч. Тәмамлык, аның төрләре. Хәл, аның төрләре.**

письменная работа, примерные вопросы:

Предикативность предложения.

**Тема 9. Аныклагыч һәм аның үзенчәлекләре.**

письменная работа, примерные вопросы:

Модальность предложения

**Тема 10. Модаль кисәкләр.**

письменная работа, примерные вопросы:

Күпнокталар урынына кереш сүзләрне куеп чыгыгыз, нинди сүз төркемнәре белән бирелүенә игътибар итегез. 1. ? , минем әтием ? композитор Салих Сәйдәшев ? әнә шундый тыйнак һәм эш сөючән кеше иде (А.Сәйдәшев). 2. Читтән караган кеше мине дә, ? , шашкан дип уйлар, ләкин мин гомеремдә дә шаша алмам? (К.Тинчурин). 3. Кеше белмәсә ярый, ? (И.Гази). 4. Ак болытлар, ? , калка башлый (Х.Туфан). 5. ? , бу кап-кара урманда һәрerтkыч та бар (Г.Тукай). Кереш сүзләр: әйтик, шөбһәсез, янәсе, күргәнегезчә, билгеле.

**Тема 11. Тиңдәш кисәкләр.**

письменная работа, примерные вопросы:

Тиңдәш кисәкләр, алар янында гомумиләштерүче сүзләр кертеп, "Минем дустымның туган көне" дигән хикәя языгыз.

**Тема 12. Җөмләнең синтагмаларга бүленеше.**

письменная работа, примерные вопросы:

Өзекләрне дөрес интонация белән укып чыгыгыз. Кайсы өзек ? әдәби стильдә, ә кайсысы фәнни стильдә язылган? Тиңдәш кисәкләрнең үзара нинди чара белән бәйләнештә торуын күрсәтегез, бу чараларның төрен билгеләгез. Текстны синтагмаларга аерыгыз. Билгеле, мондый вакытта балыклар яхшы чиртәләр, кармакны бер дә тик тотмыйлар. Таҗиның әтисе балыкларны сөйри дә чыгара, сөйри дә чыгара, ялтырап торган ап-ак чабакларны, көмеш тәңкәле кызылканатларны, әрсез алабугаларны. Таҗи аларның барысын да чиләккә җыя бара. Менә инде аларның балык сала торган чиләкләре дә тулып килә. Төшлеккә җитә башлагач, кояш бик нык кыздырырга тотынды. Монысын Таҗи да тойды, әтисе дә (А.Алиш). Киң колач белән башланган киң, салмак интонация бер бөтен булып төгәлләнсен, түгәрәкләнсен өчен, берсе янында берсе һәрберсе үзенчә һәм мәгънәне, һәм эмоциональ тәэсирлекне тагын-тагын үстерә, көчәйтә торган тиңдәш кисәкләр тезелеп китә (С.Ибраһимов).

**Тема 13. Аерымланган иярчен кисәкләр.**

письменная работа, примерные вопросы:

Текстны укыгыз. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз. Аерымланган кисәкләрне билгеләгез. Кошлар рәхмәте Бер төлке ? хәйләкәр җанвар ? кыр үрдәген оясыннан йолкып алып, урманга чаба. Аны бер абый күреп кала. Борчылып, шул урынга ашыга ул. Анда, ягъни ояда, ун йомырка күрә. Йортына алып кайтып, аларны кыртлап йөргән тавык астына сала. Бераздан ун бәбкә борын төртеп чыга. Тавык үз вазифасын җиренә җиткереп үти: җәй буе чебешләрен (бәбкәләрен) иярТеп йөри, хәвеф-хәтәрдән саклый. Кошлар (әлеге үрдәк бәбкәләре) үсә шулай. Җәй уза, һәм көз җитә. Бер көнне бәбкәләр, җирне калдырып, һавага күтәреләләр дә оча башлыйлар. Тавык, тревога игълан итеп кычкырса-кытакласа да, берни эшли алмый. Тавыкны кызганса да, хуҗа моңа борчылмый. Шулай кирәклеген аңлый ул. Ә үрдәкләр, тавык белән хуҗага рәхмәтләрен белдереп, йорт өстендә берничә түгәрәк ясап, тыйнак кына бакылдашып, көньякка юл тоттылар. Шулай итеп, җәйге изгелекнең әрәмгә китмәвен сиздергәннәр алар. /Ә.Баянов/

**Тема 14. Җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше.**

письменная работа, примерные вопросы:

Актуаль кисәкләрнең өйрәнелеше, текстта чылбырлы бәйләнеш.

**Тема 15. Җөмләдә сүз тәртибе.**

письменная работа, примерные вопросы:


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Уңай һәм кире сүз тәртибе, инверсия күренешенең сөйләмдә һәм әдәби телдә кулланылышы.

**Тема 16. Өстәлмәләр. Тематик баш килешле әйләнмә.**

письменная работа, примерные вопросы:

Аерым синтаксик берәмлек буларак өстәлмәләр, аларның өйрәнелеше.

**Тема 17. Җөмлә төрләре. Раслау Һәм инкяр җөмләләр. Хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмләләр. Тулы һәм ким җөмләләр. Җыйнак Һәм җәенке җөмләләр.**

письменная работа, примерные вопросы:

Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, төрләрен билгеләгез. Җөмләләргә билгеләмә бирегез. Мәдинә Өй буенда бөдрәләнеп үскән яшь каенга карап, Мәдинә тирән уйга калды. Нинди нәфис, назлы булып үсеп килә ул! Мәдинә табигатьнең матурлыгына сокланып туя алмый. Тик бүген аның яшь йөрәген ниндидер татлы, ләззәтле сагыш баскан. Ул үзенең авылдагы әнисен, бала чакта бергә үскән дусларын сагына. Аның күңеле авылга, алар янына ашкына. Кайчан гына имтиханнар бетәр икән? Бәлки, бер генә атнага булса да, әнием янына кайтып килер идем. Кочагыма алып, кысып-кысып сөяр идем үзен, иркәләр идем. Куаныр иде дә соң әнием! Нинди ягымлы, сөйкемле карчык ул минем әнием! Ә үзе нинди олы җанлы! Шул кечкенә генә гәүдәле әнием берсеннән-берсе таза, берсеннән-берсе чибәр дүрт егет, бер кыз үстергән. Миңа ул әле һаман, нәнием, ди. Мин аның төпчек кызы! Шуңамыдыр, мине һаман кечкенә итеп күрәсе килә. Ә үзе хәзер иягемнән генә булып калды. Әнием инде бик картайган. Сугышта үлгән әтим белән олы абыемның сагышы аның йөзендәге алсулыкны гомергә җуйган, чәчләренә чал кергән. Никадәр генә яхшы тәрбиядә яшәсә дә, көннән-көн картайган төсле күренә. Аны сабый баладай иркәлисе, ягымлы сүзләр әйтеп, күңелен юатасы килә. Мәдинә, шундый татлы хыялларга бирелеп, өстәл яныннан сикереп торды да, өстенә жакетын киеп, урамга чыкты. Аның әле башыннан кичергән бөтен сагышы, хыялы кулындагы зәңгәр конверт эченә бүленеп салынган иде. /Ә.Бикчәнтәева/

**Тема 18. Җөмлә төрләре. Бер составлы җөмләләр. Ике составлы җөмлә узенчәлекләре.**

письменная работа, примерные вопросы:

Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, төрләрен билгеләгез. Җөмләләргә билгеләмә бирегез. Яшь имәннең төбен йомшартып, яфракларын сөртеп торганда, әрәмә башындагы Олы күл ягыннан кинәт кенә җиз торбадан чыккандай калын һәм яңгыравыклы аккош тавышы ишетелде. Бу моңлы һәм матур тавыш тәгәрәк алан өстеннән тагын яңгырап китте. Аңа икенче аккош тавышы кушылды. Өченче, дүртенче! Инде дүрт аккош берьюлы кычкыра башлады. Без шатлыктан ни әйтергә дә белмәдек. Чөнки бу Олы күлдә гомер-гомергә пар аккош яши иде. Кояшлы халкы аларны бик ярата һәм чит авыллар алдында горурлана, бала-чага шикелле мактанып та куя иде. Ләкин әрәмәне кискәннән соң, алар Олы күлне ташлап китте. Яз көне ничә еллар буе гомер иткән, нәни балалар чыгарган оялары өстеннән моңсу һәм кайгылы тавыш белән кычкыра-кычкыра очып йөргәннәрен күрүчеләр булган. Тик алар суга төшмәгәннәр. Моңланып кычкыра-кычкыра, чит-ят җирләргә очып киткәннәр.

**Тема 19. Кушма җөмлә.**

**Тема 20. Тезмә кушма җөмлә.**

письменная работа, примерные вопросы:

Аерымланган хәлләр белән килгән гади җөмләләрне һәм кушма җөмләләрне аерып языгыз. 1. Күктә, бозлы миләшләрне хәтерләтеп, тәлгәш-тәлгәш йолдызлар кабынды. (Р.Низамиев) 2. Сабан туйлары җитә башласа, йокысы, ялы онытыла иде. (А.Гыйләҗев) 3. Әнә белән кое казыган шикелле байтак тырышты ул. (Р.Низамиев) 4. Алда озын кыш булса да, авыл инде яз турында уйлый башлады. (А.Гыйләҗев) 5. Ул, һәрвакыттагыча, олы тыйнаклык һәм сабырлык белән ашыкмыйча гына атлап, Айсылу янына килеп басты. (Ә.Сәлах) 6. Безнең базарга, сатарга дип, бер чиләк май алып киләләр иде. (З.Зәйнуллин) 7. Мәктәпне тәмамлагач, Алабуга педучилищесына имтихан тота. (М.Галиев) 8. Бакча якта түземсезлек белән батырлык кылыр минутны көтеп торган малайлар, ?урра? кычкырып, бер-берсен төрткәләшеп, дәррәү кәҗәгә таба йөгерделәр. (Р.Мөхәммәдиев) 9. Илдар йокыга киткәч, Әнисә, бүген булган хәлләрне башыннан уздырып, йокыга китә алмыйча интекте. (Т.Галиуллин) 10. Ә менә Клараның әтисе, шул авылда туып-үскән булса да, Каракошны сагынып бер дә телгә алмый иде. (Ә.Еники) 11. Хәйрулла абзый үзе хикмәтлерәк итеп сөйләшсә дә, Бибиҗамал икенчерәк итеп сөйләшә иде. (М.Мәһдиев) 12. Дөнья үз канунына тотрыклы шул: бер кергән суга яңадан кереп булмый. (М.Галиев)

**Тема 21. Иярченле кушма җөмлә. Иярченле кушма җөмлә үзенчәлекләре.**

письменная работа, примерные вопросы:

Иярченле кушма җөмләләрне синтетик һәм аналитик төрләргә аерыгыз. Өлкән буын телне салмак олыгайтып яшәтсә, яшь буын телне санлап яшәртә. (М.Галиев) 2. Шушы табыгый бизмәннең ике яссылыгы да тигез тибрәнештә булганда гына телнең тере сулышы бөтен мөмкинлегенә киерелеп ачыла. (М.Галиев) 3. Җан кадерле, дуслар, сугышта, Сугышырга чөнки җан кирәк. (Ф.Кәрим) 4. Ничек миңа бирделәр, сезгә дә шул килеш тапшырам. (Р.Газизуллин) 5. Ае юк төннең йолдызлары болытларга күмелгән. (Һ.Такташ) 6. Корт анасы кайда кунса, күче шунда сарыр. (Мәкаль) 7. Әнисе әйтеп өлгергәнче, Хәлим чыгып та китте. (А.Гыйләҗев) 8. Ул елны көз бик коры килде, шуңа күрә кыр эшләре дә тиз бетте. (Г.Галиев) 9. Күккә карап алгач, ул шаккатты: болытлар гадәттә булмый торган куе яшел иде. (Э.Касыймов) 10. Ярдәм кирәк булса, мин әзер. (М.Юныс)

**Тема 22. Иярчен ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык җөмләләр.**

письменная работа, примерные вопросы:

Гади, тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрне аерыгыз. Шул мине әсир итте, шул миңа сөю тылсымы бирде. (Г.Гыйльман) 2. Менә зәңгәр күктә сарык бәтиләре төсле, ике ак болыт бер-берсен сөзделәр дә акрын гына бергә кушылып эределәр һәм кояшка таба шуыштылар. (Ф.Садриев) 3. Менә кич булды, вальс кичәсенә төшәр вакыт җитте. (Ә.Салах) 4. Чәчәкләрнең нигә кирәге бар, өзеп бирер кешең булмаса?! (Н.Измайлова) 5. Уңган җиңгәчәсе егет белән кызның яратышып йөргәнен күрергә тиеш иде. (Ә.Еники) 6. Шау-гөр килеп су коенып ятканда, кинәт өстебездән кара шәүлә очып узды. (М.Галиев) 7. Зәңгәр күк астында әле дә сугыш һәм тынычлык дигән ике төшенчә янәшә тора. (Р.Мөхәммәдиев) 8. Битләрем янып чыга, маңгаема бөрчек-бөрчек тир бәрә. (Ә.Галиев) 9. Аның инде кул һәм аяклары сизми, кузгалмый, салкын һәм авыр ташлар шикелле түбән тарталар... (Ш.Камал) 10. Фәһим яңадан урамга чыкканда, тулган ай үзенең көянтә-чиләкле кызы белән мәчет кыегына ук якынлашып килә иде инде. (Г.Бәширов)

**Тема 23. Иярчен урын, вакыт, рәвеш, күләм җөмләләр.**

письменная работа, примерные вопросы:

Гади, тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрне аерыгыз. Үткәннәрне хәтерләтеп, күңелләрне дәртләндереп сайрасын гармун! (М.Абдуллин) 2. Кәрим үз күзләренә үзе ышанмады: бәрәңге бакчасы бер төн эчендә тәмам үзгәргән, яктырып, нурланып киткән иде. (Р.Низамиев) 3. Тукай ? шагыйрь генә түгел, ул ? публицист һәм журналист, тәнкыйтьче, фольклорчы, тәрҗемәче, сәясәтче, педагог та. (Х.Миңнегулов) 4. Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, күзләреннән кайнар яшь бәреп чыкты. (Г.Бәширов) 5. Ә давыл артыннан килгән бәрәкәтле яңгыр тәүлек буена бер әкренәеп, бер шәбәеп туры гына яуды да яуды. (Ә.Еники) 6. Мин ул күрсәткән өйгә керергә дип селтәнеп ишекне тарткан идем ? уянып киттем. (Ш.Камал) 7. Су өстенә төшкән агач күләгәләре озыная башлагач, Рәхим, рюкзакны тотып, аягына басты. (Р.Бәшәр)

**Тема 24. Иярчен сәбәп, максат, шарт, кире җөмләләр.**

письменная работа, примерные вопросы:

Гади, тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрне аерыгыз. 1. Чабылган печәнне таратып бетергәч, юкәлек күләгәсенә кереп ялга, көндезге ашка туктыйбыз. (Р.Мөхәммәдиев) 2. Әмма яшьлек ярсуыннан тау чишмәседәй ургып торучы йөрәккә ана назы гына аз, ана кайгыртуы гына җитми. (Ф.Яруллин) 3. Җил кайдан исә, болыт та шуннан килә. (Мәкаль) 4. Берәм-сәрәм очраган усакларның көмеш яфраклары, таң сулышыннан уянышып, сөенә-сөенә уйнаган шикелле, җилфердәшәләр... (Ә.Еники) 5. Ачык урыннарда, җиргә сыгыла төшеп, хәрәкәтсез ак томан ята. (Ә.Еники) 6. Дәртле кояш кытыклап уяткандай, табигать тирләп, көлеп күзен ачты. (Ә.Еники)

**Тема 25. Иярчен аныклагыч, кереш, өстәлмә җөмләләр.**

письменная работа, примерные вопросы:

Һәр җөмләнең баш кисәкләрен табыгыз, компонентларның чикләрен билгеләгез, схемаларын сызып, тулы билгеләмә бирегез: 1) Күктә болыт парлы булып Йөзеп барган җиреннән Ике якка аерылса, Яшем тама күземнән (Ш.Җиһангирова). 2) Көн салкынчарак булса да, күктәге нурлы кояш күңелләрне җылытып, дәртләндереп тора (Г.Гыйльманов). 3) Ләкин кешелек тормышы шулай корылган инде: бер борчу артыннан икенчесе, өченчесе килә дә җитә... (Г.Гыйльманов). 4) Алмагачта ничә яфрак булса, Шулкадәрле йөрәк бар миндә (Г.Гыйльманов).

**Тема 26. Аналитик һәм синтетик бәйләүче чаралар.**

письменная работа, примерные вопросы:

Һәр җөмләнең баш кисәкләрен табыгыз, компонентларның чикләрен билгеләгез, схемаларын сызып, тулы билгеләмә бирегез: 1) Кеше үзе теләгән кадәр генә бәхетле була! (Г.Гыйльманов). 2) Алар киткән якта тузан болыты гына бөтерелеп калды (Ф.Шәфигуллин). 3) Җил ялгыз йөрми: озакламый кар ява башлады (И.Гази). 4) Туплар тынсын өчен утка керде, Яуга керде Фәрит Яруллин (Р.Вәлиев). 5) Сыгылма такталар арасында күп вакыт чабата кысылып калучан була, шуңа күрә ташучылар күпердән бик сакланып, туры барырга тырышалар (Ф.Сәйфи-Казанлы). 10) Истә тот: былбыллар Сайрамый гел генә (Ф.Яруллин).

**Тема 27. Кушма җөмләләрне бер төзелештән икенче төзелешкә үзгәртү.**

письменная работа, примерные вопросы:

Авырлыкны үлчәр өчен Үлчәү бар, Сабырлыкны үлчәр өчен Үлчәү юк (Ф.Яруллин). Әлеге шигъри юлларга үз мөнәсәбәтегезне белдереп, гади һәм ике компонентлы кушма җөмләләрдән хикәя төзеп языгыз.

**Тема 28. Аналитик та, синтетик та булган кушма җөмләләр.**

письменная работа, примерные вопросы:

Һәр җөмләнең баш кисәкләрен табыгыз, компонентларның чикләрен билгеләгез, схемаларын сызып, тулы билгеләмә бирегез: 1) Ал яулыгын болгап китеп бара Ал болытлар кояш батышка (Ф.Яруллин). 2) Хәтереңдәме: тышта коеп-коеп Яңгыр ява иде (Ш.Җиһангирова). 3) Җил-давыллар каршы тора алмас, Тотынышып барсак кулга-кул (Ш.Җиһангирова). 4) Иң гаҗәбе шул: бүген аның бер җире дә авыртмый (Г.Гыйльманов). 5) Басуларның саф һавасы белән Чистарганда каннар, үпкәләр, Онытыла тормыш ваклыклары, Күңелдәге рәнҗү, үпкәләр... (Ш.Галиев).

**Тема 29. Күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә.**

письменная работа, примерные вопросы:

Һәр җөмләнең баш кисәкләрен табыгыз, компонентларның чикләрен билгеләгез, схемаларын сызып, тулы билгеләмә бирегез: 1. Кайчак сөю давыллары Алсалар да бөтереп, Дөньяның бар матурларын Булмый сөеп бетереп (Р.Миңнуллин). 2. Мең эшемне ташлап, кабат-кабат Авылыма кайткан саен мине Мәңге шулай капка төбебездә Әткәм-әнкәм каршы алса иде (Ш.Җиһангирова). 3. Ата-ана кадерен аңлар-белер өчен, Аллаһы Тәгалә адәм баласына балалар биргән (Ш.Җиһангирова). 4. Әллә нинди ялтыравык челтәр белән бизәлгән сары капканың уң ягында ? әлеге карт әйткән матур ишек... (К.Нәҗми). 5. Сине кемдер һаман сагынып яши, Син кемнедер сагынып яшисең (Г.Гыйльманов).

**Тема 30. Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.**

письменная работа, примерные вопросы:

Мәрхәмәтне үлчәргә дә Бизмән юк, Мәхәббәтне үлчәргә дә Бизмән юк (Ф.Яруллин). Әлеге шигъри юлларга үз мөнәсәбәтегезне белдереп, гади һәм ике компонентлы кушма җөмләләрдән хикәя төзеп языгыз.

**Тема 31. Текст.**

письменная работа, примерные вопросы:

Иярченле кушма җөмләләрне укыгыз, баш кисәкләрнең асларына сызып, җөмлә чикләрен билгеләгез. Җәяләр эчендә баш һәм иярчен җөмләләрне билгеләп барыгыз. 1. Картлар дөнья куйганнан соң [...], әлеге ике гаилә үз көнен үзе күрергә тиеш иде [...]. (Г.Бәширов) 2. Роза ничек кинәт кенә кергән булса [...], ул шулай кинәт кенә чыгып та китте [...]. (Г.Минский) 3. Фәһим килеп җиткәндә [...], халык ярыйсы ук җыелган иде инде [...]. (Г.Бәширов) 4. Кем җиңүче була [...], кулъяулык шуңа [...]! (Э. Касыймов) 5. Телең ни әйтсә [...], колагың шуны ишетер [...]. (Мәкаль) 6. Офык читендә каралҗым болыт куера башладымы [...], өйнең берәр почмагына кереп качам [...]. (А.Гыйләҗев) 7. Балалар кайтуга дип [...], <...> түбән әйберләр өстәлдә урын алды [...]. (Г.Гобәй)

**Тема 32. Тезем.**

письменная работа, примерные вопросы:


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Җөмләләрне укыгыз һәм схемасын сызыгыз 1. Йөри-йөри күңеле тупасланса, Тузан кунса яшьлек хисенә, Бер сафланып алыр өчен тагын Туган ягы кирәк кешегә. (Фәнис Яруллин). 2. Йөрәкләре бергә типмәсә дә, Парлашалар күпме ялгызлар, Шуңа арабызда меңәрләгән Парлы булып йөргән парсыз бар. (Зөһрә Шакирова). 3. Иртән чыксам, күзләр камаша: Мамык карлар җирне каплаган. (Шәүкәт Галиев). 4. Җилләр йошак, таңнар якты, офыклар киң, Чөнки бит сез сөясез һәм сөеләсез. (Фәнис Яруллин). 5. Үкенмәмен җирдән китүемә, Үземнән соң миннән әйбәтрәк Балаларым калса, Җан дусларым килеп каберемә Бер уч туфрак салса... (Шәмсия Җиһангирова). 6. Дөньялыкта усал җилләр уйный, һавада кара болытлар йөзә, йолдызлар тоныклана, кошлар кыяга бәрелеп үлә, сулар агулана, язмышлар иясез кала, кешеләр адаша... (Галимҗан Гыйльманов).

**Тема 33. Чит сөйләмле текст.**

письменная работа, примерные вопросы:

Җөмләләрне укыгыз һәм схемасын сызыгыз 7. Син киләсе юлдан Кара мәче ? кара төн уза, Ә мин һаман күктән кояш көтәм, Ә мин һаман көтәм могҗиза (Рәзил Вәлиев). 8. Күтәрелә барган саен сулышы ешаеп, адымнары әкренәйделәр аның (Габдрахман Минский). 9. Иң аянычлысы шунда: явыз җаннар белән бергә әйбәт кешеләр дә, изге җаннар да һәлакәткә очрыйлар, хөрмәткә, ихтирамга лаек ил агалары да, бер гөнаһсыз сабый балалар да үлемгә дучар ителәләр... (Галимҗан Гыйльманов). 10. Йөрәк теләсә кемгә ачылмый, йөрәккә ярату ачкычы яратып булмый, йөрәккә ярату ачкычы кирәк: йөрәкне яратып кына ачып була. (Марсель Галиев). 11. Дуслар белән күрешкәндә, Егыла-егыла көлешкәндә, Шатлыкларны бүлешкәндә, Әгәр кинәт күңелем тулса, Күзләремдә яшьләр булса, Тиргәмәгез, Кичерегез! (Фәнис Яруллин).

**Тема 34. Пунктуация. Синтаксисны өйрәнү тарихы.**

письменная работа, примерные вопросы:

1 нче бирем. Җөмләләргә тиешле тыныш билгеләрен куеп чыгыгыз. 1. Без өйгә кайтып кергәндә кояш баеп бара иде инде. (М.Гафури) 2. Төн буе буран котырганга юл бик начар иде. (И.Гази) 3. Ул үзенең егетләре белән урманга килеп җиткәндә урман авызында аны шул ук Гыйльметдин каршы алды. (И.Гази) 4. Ае юк төннең йолдызлары болытларга күмелгән. (Һ.Такташ) 5. Аптырап Хәлимә ягына борылсам кыздан җилләр искән. (Ф.Шәфигуллин) 6. Кайчагында аның күңеле күз яшьләре чыгарлык дәрәҗәдә аеруча бер җилкенү белән дулкынлана башлый. (Г.Бәширов) 7. Урман каравылчысы түбәдән кар ишелгән шикелле тавыш белән дөбердәтеп көлде. (М.Галиев) 8. Зөһрә ханым минем белән бергә китергә риза булгач күңелемне аеруча бер рух күтәренкелеге биләп алган иде. (Ә.Еники) 9. Дөнья киңлегеннән ни файда аяк киемең тар булса? (Мәкаль) 10. Үзеңне әдәбият чаклы әдәбияттан халык рухының көзгесе булган әдәбияттан өстен куярга азаплану берәүне дә бизәми минемчә. (Г.Ахунов)

**Тема . Итоговая форма контроля**

Примерные вопросы к экзамену:

Рекомендации по выполнению плана самостоятельной работы

Особенностью дисциплины "Синтаксис современного татарского языка" является самостоятельная работа студентов, связанная с изучением проблемных вопросов по некоторым темам лекций.

Проверка выполнения плана самостоятельной работы проводится на практических занятиях.

Самостоятельная работа студентов по курсу призвана не только закреплять и углублять знания, полученные на аудиторных занятиях, но и способствовать развитию у студентов творческих навыков, инициативы, умению организовать свое время и выразить свою точку зрения на изученные проблемные вопросы.

При выполнении плана самостоятельной работы студенту необходимо прочитать теоретический материал не только в учебниках и учебных пособиях, указанных в библиографических списках, но и познакомиться с публикациями в периодических изданиях.

Студенту необходимо творчески переработать изученный самостоятельно материал и представить его для отчета в форме реферата, эссе и др.

Темы рефератов

1. Семантический (номинативный) синтаксис.

2. Актуальный синтаксис.

3. Конструктивный синтаксис.
4. Средства подчинительной связи.
5. Именные словосочетания
6. Глагольные словосочетания.
7. Грамматические схемы и модели простого предложения.
8. Предикативность предложения.
9. Модальность предложения
10. Порядок слов в в прозаической письменной речи.
11. Синтагматическое членение предложения.
12. Сложноспаянные предложения
13. Сложноподчиненные предложения.
14. Многочленные сложные предложения.
15. Синтаксис текста.

Контрольные вопросы и задания для проведения текущего контроля и промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины

Тесты (с элементами задания) для проведения контрольной работы

Гади җөмлә

1. Бер составлы фигыль җөмләгә карамаган төрне күрсәтегез:

а) билгеле үтәүчеле

б) үтәүчесез

в) номинатив

г) гомуми үтәүчеле

д) билгесез үтәүчеле

2. Кыек тәмамлык булган җөмләне билгеләгез, тиешле кисәкнең астына сызыгыз:

а) Баһау шүрли төште, ләкин ул моны сиздермәс өчен елмайган булды. (Г.М.)

б) Чөнки Татарстан халкы өчен бу бик кадерле һәм истәлекле газиз көн.

в) Дөньяның серен аңлар өчен, чәчәк серен белергә кирәк. (Р.Б.)

г) Әтием дә, аны озатыр өчен, ашыгып торып басты. (Р.Б.)

3. Кушма фигыль хәбәрле җөмләне табыгыз, хәбәрнең астына сызыгыз:

а) Мин сезгә ул турыда сүз бирәм.

б) Иртә белән көн томанлы иде.

в) Ике хәзрәт, ни өчендер, извозчик ялламакчы булалар.

г) Әптелбәр, уйнарга теләсә дә, бу тәкъдимне кире какты.

4. Җөмләнең хәбәрен табыгыз: Җиңелгәнне җиңел кичерә белгән кешеләр сирәктер дөньяда (М.Галиев)

а) кичерә белгән

б) сирәктер

в) дөньяда

г) хәбәре кулланылмаган

5. Җөмләнең иясен табыгыз: Дускай, сиңа бүләк итәр идем Илкәемнең иркә гөлләрен (М.Җәлил)

а) дускай

б) ияce кулланылмаган

в) сиңа

г) гөлләрен

6. Хәбәрнең астына сызыгыз һәм структур төрен билгеләгез: Хәлим аның сөйләгән сүзләрен колагына җыеп торды (И.Гази)

а) гади фигыль хәбәр


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

б) тезмә фигыль хәбәр
в) кушма фигыль хәбәр
7. Бер составлы фигыль җөмләнең төрен билгеләгез, хәбәрнең астына сызыгыз: Сүзне алардан башларга кирәк булгандыр миңа (Р.Төхвәтуллин)
а) билгеле үтәүчеле
б) билгесез үтәүчеле
в) гомуми үтәүчеле
г) үтәүчесез
8. Тезүле бәйләнешне белдерүдә катнашмаган чараны билгеләгез:
а) тезүче теркәгечләр
б) бәйлек һәм бәйлек сүзләр
в) санау интонациясе
г) каршы кую интонациясе
9.Ике составлы җөмләне табыгыз һәм баш кисәкләрнең астына сызыгыз::
а) Умырзая җыйдык, кошлар сайравын тыңладык, рәхәтләнеп ял иттек (Г, Мөхәммәтшин)
б) Аның күзләренә ак төшкән (М.Гафури)
в) Күңелемнең сине көткән чагы.
г) Аның бертуктаусыз каядыр йөгерәсе, чабасы килә, нидер эшлисе, кырасы-ватасы килә (Н.Фәттах)
10. Күләм хәле булган җөмләне билгеләгез, тиешле кисәкнең астына сызыгыз:
а) Айбиби бертын дәшми торды. (М.Х-н)
б) Малайлар учакны шәп итеп якканнар. (Г.Б.)
в) Тиен кинәт янәшә агачка сикерде . (Ә.Ф.)
г) Тузан суыргычтай йота Кала ыгы-зыгысы. (Л.Л.)
11. Сәбәп хәле булган җөмләне табыгыз, тиешле кисәкнең астына сызыгыз:.
а) Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп.
б) Таҗи шул уйлар белән чәй янынан торды.
в) Аның әрнүдән йокылары кача иде.
г) Без яшьтән үк таныштык.
12. Иярүче сүз ияртүчедән аңлашылган процессның максатын белдергән сүзтезмәне табыгыз:

а) талантка баш ию
б) урманга бару
в) суга чыгу
г) суыкка калтырау
13. Кушма фигыль хәбәрнең астына сызыгыз һәм белдергән мәгънәсен билгеләгез: Үкенечтән сыкрап куяр җаннар (Зөлфәт)
а) модаль мәгънәне
б) процессның үтәлү дәрәҗәсен
в) эзлекле процессны
г) заман мәгънәсен
14. Ачыклаулы мөнәсәбәтне табыгыз һәм бәйләүче чараны билгеләгез:
а) гүзәлсең син
б) Тукайның, бөек шагыйрьнең
в) Кара диңгез
г) урам буеннан йөрү
15. Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре (Г.Тукай) Хәбәрнең астына сызыгыз һәм структур төрен билгеләгез:

а) гади фигыль хәбәр
б) тезмә фигыль хәбәр
в) кушма фигыль хәбәр
г) тезмә исем хәбәр
16. Аерып бирелгән сүзләр нинди җөмлә кисәге булып килә: Сезнең кебек матур ярлар авылда ла түгел,илдә юк (Халык җыры)
а) аергыч
б) кыек тәмамлык
в) күләм хәле
г) рәвеш хәле
17. Ике составлы җөмләне табыгыз, баш кисәкләрнең астына сызыгыз:
а) Онытылып ук кителгән (Ф.Хөсни)
б) Беренче класслы палубага беренче мәртәбә аяк басуыбыз (Р.Хәбибуллина)
в) Тимерне кызуында сугалар (М.)
г) Аяз иде ул көнне күк йөзе! (Г.Ахунов)
18. Аерып бирелгән сүз нинди җөмлә кисәге булып килә: Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп (Г.Тукай)
а) туры тәмамлык
б) кыек тәмамлык
в) максат хәле
г) сәбәп хәле
18. Максат хәле булган җөмләне билгеләгез, тиешле кисәкнең астына сызыгыз:
а) Менә шунда үзе өчен бик кызыклы уен уйлап тапты. (Р.Н.)
б) Бу якты йорт сезнең бәхет өчен. (Ш.М.)
в) Кешегә мәшәкать ясаганым өчен уңайсызланып, тизрәк кайтырга җыендым.(Г.С.)
г) Бәлки, ул гомерендә беренче һәм соңгы тапкыр күченеп киткән өчен үкенгәндер. (Р.С.)
19. Җөмләнең баш кисәкләре арасында нинди мөнәсәбәт урнаша?
а) хәбәрлекле
б) ачыклаулы
в) аныклаулы
20. "Татар телендә сүз тәртибе" дигән хезмәтнең авторы кем?
а) М.М.Зәкиев
б) Ф.С.Сафиуллина
в) С.М.Ибраһимов
Кушма җөмлә
1. Компонентларның санына карап, кушма җөмләләр ике төргә бүленә:
1) ____________________________________________________________
2) ____________________________________________________________
2. Гомер узмый, Без узабыз, Шул гомер буйлап. (Р.Миңнуллин) Җөмләдәге сүзтезмәләрне аерып алыгыз: ________________________________________________________
3 Компонентларының үзара нинди төр бәйләнештә торуына карап, кушма җөмләләр ике төрле була: 1) ____________________________________________________
2) ____________________________________________________
4. Баш килештәге исемнәрнең нинди җөмлә кисәге булып килүләрен асларына сызып билгеләгез: Җылы нурлары белән аны озата килгән, җемелдәшкән кар бөртекләре аша аның күзләренә өмет өстәп торган, гайрәт биргән кояш та алсуланып баерга җыена иде. (Р.Мөхәммәдиев)
5. Тезмә кушма җөмләләр, тезүле бәйләнешне тәгъбир иткән чарага карап, ике төрле була: 1)
__________________________________________________


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

2) ______________________________________________

6. ) Теркәгечле тезмә кушма җөмләләрне үзара теркәү өчен хезмәт иткән тезүче теркәгечләрнең төрләрен билгеләгез һәм мисаллар языгыз:

1) ____________________________________________________________

2) ____________________________________________________________

3) ____________________________________________________________

7. ) Әни тамак кырды, әллә нәрсәләр миңа ымлады, мин көлә-көлә егеткә сөйли бирдем.(Г.Исхакый) Тезмә кушма җөмләдәге предикатив үзәкләрне, җөмлә чикләрен билгеләгез, бәйләүче чараны атагыз:_______________________________________________

8. Компонентлары үзара санау интонациясе аша теркәлгән ике компонентлы тезмә кушма җөмләгә мисал уйлап языгыз ______________________________________________

__________________________________________________________________________

9. да/дә теркәгечле тезмә кушма җөмләне табыгыз, компонентларының предикатив үзәкләрен һәм чикләрен билгеләгез:

1) Бүген көн аяз да, болытлы да. (Г.Т.)

2) Бүтән кызлар һәммәсе дә көянтә башларына берәр, икешәр каз элгәннәр, ә кунак кызның куллары буш. (Г.Б.)

3) Моны ул үзе дә белми, башкалар да сөйләмиләр. (Г.И.)

10. Ике компонентлы тезмә кушма җөмләдәге предикатив үзәкләрне, җөмлә чикләрен билгеләгез; һәр компонентка тиешле тәртиптә билгеләмә бирегез: Ә бит хан кызы үзе дә бик яхшы укый, иллә нигәдер һәрчак мөгаллименнән укытасы килә. (М.Хәбибуллин)

1 нче җөмлә -____________________________________________________________;

2 нче җөмлә -____________________________________________________________.

11. Тезмә кушма җөмләнең, составындагы компонентлар санына карап, төрен билгелә; һәр предикатив үзәкне, җөмлә өлешләренең чикләрен күрсәт: Оча алмадым, ә менә күңелдә илаһи ашкыну - биеклеккә ашу рәхәте, хозурлыгы ымсындырып калды, мин аны татлы серем итеп күңелдә кичерәм. (Ш.Галиев) _________________________________

12. Тезмә кушма җөмләдәге предикатив үзәкләрне билгеләгез, җөмләләрнең чикләрен күрсәтегез, тыныш билгеләре куелу кагыйдәләрен языгыз: Бүтән кызлар һәммәсе дә көянтә башларына берәр, икешәр каз элгәннәр, ә кунак кызының куллары буш. (Г.Бәширов)

___________________________________________________________________

13. Ул ил өстенә төшкән кайгыны - сугыш чорын күз алдына китерде. (Г.Зәйнәшева) Җөмләдә сызык куелу кагыйдәсен языгыз: ____________________________

14. Тән зиннәте кием акыл зиннәте гыйлем. (М.) Җөмләдә тыныш билгеләрен куегыз, кагыйдәләрен языгыз: _____________________________________________________

15. Нәкъ шул вакыт күз ачыргысыз әче җил исте, ком бураны дөньяны томалады. (М.Хасанов) Җөмләнең предикатив үзәкләрен билгеләгез, өлешләренең чикләрен күрсәтегез, һәр ике төр схемасын сызыг:

16. Кушма җөмләне табыгыз, предикатив үзәкләрен, җөмлә чикләрен билгеләгез:

1) Хан сараен һәм хан мәчетен ике катлы таш диварлар белән әйләндереп алган дәһшәтле кирмән каршындагы иркен мәйдан халык белән шыгрым тулы иде.(В.Имамов)

2) Чит илләрдә күп йөрдем, Газиз башым гыйбрәт алсын дип . (Җыр)

3) Ул бераз торганнан соң өйгә керде, һәм, мендәренә капланып, әкрен генә үксеп-үксеп елый башлады. (Ш. Камал)

17. Җөмләдә тиешле тыныш билгеләрен куегыз: Укучылар казлар кебек тезелешеп бәрәңге алырга чыктылар бармады. (А.Гыйләҗев)

18. Тезмә кушма җөмләгә тулы синтаксик анализ ясагыз:

Идрис хәзрәтнең каракучкыл йөзе күл өстедәй тыныч, фәкать карашында гынаниндидер шик, икеләнү газаплары пыскып яна иде. (В.Имамов)

Задания и тексты к контрольной работы

Тәкъдим ителгән җөмләләргә тулы синтаксик анализ ясагыз.

1) Күреп торасыз: фуражы бар хуҗалыклар салам юктан интегә. (Х.Х.)

2) Без торганда, Гөлбикәнең самавыры кайнаган, коймагы пешкән иде. (Г.Ибраһимов)

3) Очрашу гаять шатлыклы булды: күпләр сөенечтән көләләр, ә кайберәүләр елыйлар иде. (Р.М.)

4) Бу урында шуны әйтим әле: ул килер алдыннан, мин бер нәрсә турында баш ваттым. (Ә.Е.)

5) Тагын шуны онытма: син антыңны бозсаң, бөтенебезне дә һәлак итәсең. (М.Нас.)

6) Кешеләр, көлешә-көлешә, каядыр ашыгалар, кемнәрдер каршы алалар, кемнәрдер озаталар. (Г.Ә.)

7) Мин дә киткәч, син дә киткәч, монда кем соң эшләр? (С.К.)

8) Сәет Вахиди йөреп чыккан авылларның, ул шакыган ишекләрнең санын әле беркем дә белми. (М.Г.)

9) Кыш көне утын булмаганлыктан, салам ягалар иде. (М.Г.)

10) Халык ятып, мәдрәсә тынгач кына, Габделбасыйр бу хатны Әхмәткә күрсәтте. (Ф.Ә.)

11) Уйнадың да очып китең
Күз күрмәгән якларга. (Э.Ш.)

12) Минем абый атларны борган арада, юл әйберләре онытылып калмасын дип, мин өйгә тагын бер тапкыр кереп чыктым. (М.Ә.)

13) Кемнең икмәге мул, кемнең халкы бер җан, бер тәндәй оешкан, шул җиңеп чыга. (Г.Б.)

14) Без авылдан чыкканда, көн матур, җил юк иде. (Г.И.)

15) Ялалары төзәлеп беткәнче дип, хәрби госпитальдән аны берничә айга авылга кайтарганнар. (А.Ш.)

16) Гөлбануның кул тамырларында куәт кайнады, нәкъ ире Закир чәнечкәнчә, дүрт-биш кибәнне, җирдән эшереп китереп, бергә өйде дә, тимер сәнәкне батырып җибәрде, чүмәлә зурлыгы күтәреп алып, арбага бәйләнгән аркылы чыбыклар өстенә китереп салды. (Г.И.)

17) Мин өнсез идем, мин бер сүз дәшәргә җөрьәт итмәдем, һәм кирәкми дә иде ул. (Ә.Е.)

18) Гөлбану бу мактаудан күңеллеләнде, үзенә сокланып карап, көзге алдында әйләнде, күзенә, битенә елмаю чыкты, шуның белән баягы елау эзе бөтенләй югалып ук китте. (Г.И.)

19) Күңеле кинәт ташу сәбәпле, кыз берни дә әйтә алмады. (Г.Ә.)

20) Урсал тайны сары сарган, Әллә шуңа кайгырам. (С.С.)

Вопросы к экзамену:

1. Синтаксис һәм логика, сөйләм һәм фикерләү арасында мөнәсәбәт. Җөмлә һәм хөкемләү. Алар арасында мөнәсәбәт.

2. Сөйләм берәмлекләре. Төп синтаксик берәмлек буларак җөмлә. Җөмләнең төп үзенчәлекләре. Хәбәрлек һәм модальлек, аларның бирелү ысуллары.

3. Синтаксис фәнендә төрле юнәлешләр.

4. Интонация һәм аның сөйләмдәге роле. Фраза басымы. Пауза. Логик басым. Тойгы басымы. Сөйләм көе.

5. Сүзләрнең синтаксик бәйләнеше. Ияртүле һәм тезүле бәйләнеш. Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар.

6. Ияртүле бәйләнеш. Аның төрләре: хәбәрлекле мөнәсәбәт, төгәлләүле мөнәсәбәт, аныклаулы мөнәсәбәт. Аларны белдерә торган чаралар.

7. Сүзтезмә турында гомуми мәгълүмат. Сүзтезмәләрнең төрләре: ирекле сүзтезмә һәм фразеологик сүзтезмә; гади сүзтезмә һәм катлаулы сүзтезмә.

8. Ия. Аның төзелеш ягыннан төрләре, белдерелүе һәм төп мәгънәләре.

9. Хәбәр. Исем хәбәрләрнең төзелеш ягыннан төрләре, белдерелүе һәм төп мәгънәләре.

10. Хәбәр. Фигыль хәбәрләрнең төзелеш ягыннан төрләре, белдерелүе һәм төп мәгънәләре.

11. Аергыч һәм аның үзенчәлекләре. Төрле сүз төркемнәре белән бирелгән аергычларның аерылмышка бәйләнү юллары.

12. Аныклагыч һәм аның үзенчәлекләре. Аныклагычлар янында тыныш билгеләре.

13. Тәмамлык һәм аның үзенчәлекләре.

14. Хәлләр. Аларның мәгънә ягыннан төрләре һәм төп үзенчәлекләре.
15. Модаль кисәкләр турында төшенчә. Аларның төп үзенчәлекләре, төрләре, бирелеше. Алар янында тыныш билгеләре.
16. Җөмләнең тиңдәш кисәкләре. Гомумиләштерүче сүзләр. Алар янында тыныш билгеләре.
17. Аерымланган иярчен кисәкләр турында гомуми мәгълүмат.
18. Гади җөмләләрне төркемләү принциплары һәм төрләре.
19. Бер составлы җөмләләрнең гомуми үзенчәлекләре, төрләре.
20. Синтагма турында төшенчә. Җөмлә кисәкләренең аерым синтагма төзи ала һәм төзи алмый торган очраклары.
21. Җөмләнең актуаль кисәкләре. Актуаль кисәкләрнең урыны.
22. Сөйләмдә сүз тәртибенең роле. Төрле сөйләм стильләрендә җөмлә кисәкләренең урыны. Сүзләрнең уңай һәм кире тәртибе турында төшенчә.
23. Раслау һәм инкарь җөмләләр. Бу төр җөмләләрнең төп билгеләре.
24. Өстәлмәләр турында төшенчә. Өстәлмәләрнең кулланылышы һәм төрләре.
25. Ким җөмләләр. Аларның кимлек сәбәбенә һәм кайсы кисәкнең кулланылмавына карап төрләре.
26. Кушма җөмлә турында төшенчә. Кушма җөмләләрне төркемләү принциплары.
27. Тезмә кушма җөмлә үзенчәлекләре. Тезмә кушма җөмләләрнең үзара бәйләнешендә теркәгеч һәм интонацияләрнең роле.
28. Җөмләләр арасында ияртүле бәйләнешне белдерә торган чаралар.
29. Җөмләләр арасында мәгънәви һәм структур бәйләнеш. Җөмләләр арасында грамматик бәйләнеш һәм аның төрләре.
30. Җөмләләрне бәйли торган чара буларак интонация (санау интонациясе, каршы кую интонациясе, көттерү интонациясе, аныклау интонациясе).
31. Иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли торган чара буларак ияртүче теркәгечләрнең һәм теркәгеч сүзләрнең үзенчәлекләре.
32. Иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли торган чара буларак мөнәсәбәтле сүзләрнең үзенчәлекләре.
33. Иярчен җөмләләрне бәйләнеш төренә карап төркемләү. Аналитик иярчен җөмлә үзенчәлекләре. Бу төр җөмләләрдә тыныш билгеләре.
34. Иярчен җөмләләрне бәйләнеш төренә карап төркемләү. Синтетик иярчен җөмлә үзенчәлекләре. Бу төр җөмләләрдә тыныш билгеләре.
35. Иярчен ия һәм хәбәр җөмлә үзенчәлекләре, аларның баш җөмләгә бәйләнү юллары.
36. Иярчен аергыч җөмлә үзенчәлекләре, аның баш җөмләгә бәйләнү юллары.
37. Иярчен тәмамлык җөмлә үзенчәлекләре, аның баш җөмләгә бәйләнү юллары.
38. Иярчен аныклагыч һәм кереш җөмлә үзенчәлекләре, аның баш җөмләгә бәйләнү юллары.
39. Иярчен вакыт һәм урын җөмләләр. Аларның баш җөмләгә бәйләнү юллары.
40. Иярчен рәвеш һәм күләм җөмлә үзенчәлекләре, аларның баш җөмләгә бәйләнү юллары.
41. Иярчен сәбәп һәм максат җөмләләр, аларның баш җөмләгә бәйләнү юллары.
42. Иярчен кире һәм шарт җөмлә үзенчәлекләре, аларның баш җөмләгә бәйләнү юллары.
43. Аналитик һәм синтетик кушма җөмләләрнең үзара синонимлыгы, аларны берсен икенчесенә әйләндерү юллары.
44. Катлаулы кушма җөмлә төрләре: күп тезмәле кушма җөмлә, күп иярченле кушма җөмлә һәм катнаш кушма җөмлә.
45. Күп иярченле кушма җөмлә. Аның төрләре
46. Катнаш кушма җөмлә структурасы. Катнаш кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре.
47. Тезем. Аның интонацион үзенчәлеге, өлешләре, теземдә тыныш билгеләре.
48. Уртак һәм кыек сөйләм, аларның төп үзенчәлекләре. Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерү.
49. Чит сөйләм турында төшенчә. Чит сөйләм төрләре. Туры сөйләмнең төп үзенчәлекләре.

50. Текст турында төшенчә. Текстның төрләре, аның мәгънәви, коммуникатив, структур бөтенлеге. Композициясе.

### 7.1. Основная литература:

Татарча сөйләшик = Давайте говорить по-татарски = Let's speak tatar : [уку әсбабы] / К. С. Фәтхуллова, Ә. Ш. Юсупова, Э. Н. Денмөхәммәтова ; [ф. ред. Р. Р. Җамалетдинов ; инглиз тел. тәрҗ. Д. Р. Шәрифуллина] .? Казан : Татарстан китап нәшрияты, 2012 .? 310 б.

Мирзагитов Р.Х.. Сагдиева Р.К. Современный татарский язык. Синтаксис http://tulpar.kfu.ru/course/view.php?id=419

Синтаксис современного русского языка : учебное пособие / А.Ю. Чернышева ; Казан. (Приволж.) федер. ун-т, Филол. фак. ? Казань : [Казанский университет], 2011 .? 159 с.

### 7.2. Дополнительная литература:

Татар синтаксисы : югары уку йортлары өчен дәреслек / М. З. Зәкиев .? Казан : Мәгариф, 2008 .? 398

Юсупова Ә.Ш., Нәбиуллина Г.Ә., Денмөхәммәтова Э.Н., Мөгътәсимова Г.Р. Татар теленнән практикум. - Ихлас, 2009. - 182 б.

Урта мәктәптә татар теле укыту. Гади җөмлә синтаксисы : 7-11 нче сыйныф укытучылары өчен кулланма / Н. В. Максимов, З. В. Шәйхразиева .? Казан : Мәгариф, 2008 .? 111 б.

Татар теленең диалектлар синтаксисы тарихыннан / Л. Янсаева // Фән һәм тел = Наука и язык : Фәнни-хәбәри журнал / Казан шәһәре хакимиятенең җәмәгать оешмалары һәм ММЧ белән элемтә идарәсе; Татарстан Фәннәр Академиясе; Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты; Казан дәүләт архитектура-төзелеш академиясе .? Казань., 2006 .? �4 .? Б. 50-52.

### 7.3. Интернет-ресурсы:

www.gramota.ru - Грамота.ру

www.gumer.info - Библиотека Гумер - гуманитарные науки

www.rsu.ru - Электронная библиотека и материалы сайта КПФУ

www.slovari.ru - Электронные словари

www.wikipedia.ru - Универсальная энциклопедия

### 8. Материально-техническое обеспечение дисциплины(модуля)

Освоение дисциплины "Синтаксис современного татарского языка" предполагает использование следующего материально-технического обеспечения:

Компьютерный класс, представляющий собой рабочее место преподавателя и не менее 15 рабочих мест студентов, включающих компьютерный стол, стул, персональный компьютер, лицензионное программное обеспечение. Каждый компьютер имеет широкополосный доступ в сеть Интернет. Все компьютеры подключены к корпоративной компьютерной сети КФУ и находятся в едином домене.

Для проведения занятий по "Синтаксису современного татарского языка" необходимы учебная и учебно-методическая литература, сборники текстов произведений татарских писателей и поэтов, а также демонстрационные материалы.



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Необходимы следующие технические средства:

1. Мультимедийный компьютер с выходом в Интернет, с пакетом прикладных программ (текстовых, графических, презентационных).
2. Мультимедиапроектор.
3. Сканер.
4. Принтер.
5. Копировальный аппарат.
6. Ноутбук.

Программа составлена в соответствии с требованиями ФГОС ВПО и учебным планом по направлению 032700.62 "Филология" и профилю подготовки Прикладная филология (Татарский язык и литература, информационные технологии) .



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Автор(ы):
Сагдиева Р.К. ____________________
"__" _________ 201 __ г.

Рецензент(ы):
"__" _________ 201 __ г.